# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## 1997 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында

1 статья. 1997 елга Татарстан Республикасының республика бюджетын чыгымнар буенча - 12964902 млн.сум күләмендә һәм керемнәр буенча 11489158 млн.сум күләмендә расларга.

1997 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты кытлыгының иң чик күләмен 1475744 млн.сум күләмендә билгеләргә.

Татарстан Республикасының 1997 елгы республика бюджеты кытлыгын каплау өчен, дәүләтнең кыйммәтле кәгазьләр эмиссиясе керемнәрен дә исәпләп, 1400000 млн.сум күләмендә эчке финанслау чыганакларын җәлеп итәргә.

2 статья. 1997 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты керемнәре өстәлгән бәяләргә салым, акцизлар, предприятиеләрдән һәм оешмалардан табышка салымның бер өлеше, физик затлардан керем салымының бер өлеше, башка салым түләүләре һәм җыемнар хисабына барлыкка килә,дип билгеләргә.

3 статья. 1997 елда җир өчен салымны исәпләгәндә 1996 елда гамәлдә булган ставкаларга карата 2 коэффициентын кулланырга.

4 статья. Файдалы казылмаларны чыгарган өчен түләүләрнең ставкаларын чыгарылган табигый байлыкны сатудан килгән бәяләргә карата түбәндәге процентларда билгеләргә (моңа өстәлгән бәяләргә салым һәм акцизлар керми):

| Файдалы казылмаларның (чималның) төрләре | Ставка |
|---|---|
| 1. Нефть һәм газ | 6 |
| 2. Табигый битум | 4 |
| 3. Гипс ташы | 4 |
| 4. Фосфоритлар | 4 |
| 5. Цемент чималы | 4 |
| 6. Туфракны известьлау өчен карбонат токымнары | 3 |
| 7. Карбонат токымнары | 3 |
| 8. Киселгән таш | 3 |
| 9. Бут һәм вак таш әчен төзелеш ташы | 3 |
| 10. Ком-гравий катнашмасы | 4 |
| 11. Пыяла һәм формалау комы | 4 |
| 12. Төзелеш комы | 3 |
| 13. Бентонит балчыклары | 4 |
| 14. Керамзит балчыклары | 4 |
| 15. Кирпеч балчыклары | 2,5 |
| 16. Глауконитлар, цеолитлар | 4 |
| 17. Торф, торфовивианит | 3 |
| 18. Җир асты сулары | 6 |

1997 елда җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр бюджет дәрәҗәләре буенча түбәндәгечә бүленә, дип билгеләргә (%):

| Түләүләрнең төрләре | Бюджетлар буенча бүленеш | |
|---|---|---|
| | республика | районнар (шәһәрләр) |
| 1. Файдалы казылмаларны чыгарган өчен түләүләр | - | - |

| | | |
|---|---|---|
| - торф, сапропель, җир асты сулары һәм шифалы сулар буенча; | - | 100 |
| - киң таралган файдалы казылмалар буенча; | - | 100 |
| - нефть, газ, Идел һәм Кама елгалары үзәннәреннән чыгарылучы ком-вак таш катнашмасы, табигый битум, гипс ташы, цемент чималы буенча; | 70 | 30 |
| - файдалы казылмаларның калган төрләре буенча (фосфоритлар, бентонит балчыклары, керамзит балчыклары, төзелеш известе өчен карбонат токымнары, киселгән таш, пыяла һәм формалау комы, глауконитлар, цеолитлар) | - | 100 |
| 2. Файдалы казылмаларны лицензияләрдә билгеләнгән лимитлардан (квоталардан) тыш кулланган өчен түләүләр, 5 мәртәбәгә артыграк ставка буенча алына; | 60 | 30 |
| - нормативлардан тыш кулланылыш билгеләгән орган исәп-хисабына - 10% | | |
| 3. Файдалы казылмаларны чыгаруга бәйле булмаган җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр | 50 | 50 |

5 статья. Дәүләт мөлкәтен һәм коммуналь мөлкәтне хосусыйлаштырудан килгән акчалар, реинвестицияләүгә җибәрүне исәпкә алып, төрле дәрәҗәдәге бюджетлар һәм хосусыйлаштыру фондлары

арасында түбәндәге нормативлар буенча бүленә:

а) фондлар һәм бюджет арасында:

(процентларда)

| | хосусыйлаштыру фондларына | Татарстан Республикасы бюджетына |
|---|---|---|
| Хосусыйлаштырудан килгән гомуми сумма | 10 | 90 |

б) төрле дәрәҗәдәге бюджетлар арасында:

(процентларда)

| Хосусыйлаштыру объектларыннан | Татарстан Республикасының республика бюджетына | җирле бюджетларга |
|---|---|---|
| республика милкен | 70 | 30 |
| коммуналь милекне | 30 | 70 |

<u>6 статья.</u> Татарстан Республикасы бюджетына кертелүче табышка (керемгә) салым ставкасын түбәндәгечә билгеләргә:

а) предприятиеләр, оешмалар һәм чит илләрнең хокукый затлары өчен - 22 процент күләмендә;

б) предприятиеләр өчен - арадашчы гамәлләреннән, сәүдә килешүләреннән алынган табыш буенча, биржалар, брокер конторалары, банклар, кредит һәм иминләштерү оешмалары өчен - 30 процент күләмендә.

<u>7 статья.</u> Татарстан Республикасы бюджетына барлык төр салымнарын тулысынча һәм вакытында акчалата түләүче предприятиеләргә һәм оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетына кертелә торган табышка салым ставкасын 5 процентлы пунктларга киметер-

гә.

<u>8 статья.</u> Предприятиеләрнең, оешмаларның һәм чит ил хокукый затларының мөлкәткә салым буенча ставкасын салым салынучы базаның 2 проценты күләмендә билгеләргә.

1997 елда физик затларның мөлкәтенә салым ставкасын корылмаларның, биналарның, төзелмәләрнең инвентаризация бәясенең 0,1 проценты күләмендә билгеләргә.

<u>9 статья.</u> "Татнефть" акционерлар җәмгыятенең өстәмә нефть чыгаруын кызыксындыру максатында:

1. Зыян китереп эшләүче кече дебитлы һәм күп сулы скважиналардан алты млн.тонна нефть чыгарырга - нефтьнең һәр тоннасына акциз җыемнарын 15 мең сумга кадәр киметү, чыгарылган файдалы казылмалар өчен түләүнең Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелә торган өлешендә 50 процентка киметү хисабына скважиналарны һәм зыянга эшләүче кече дебитлы һәм күп сулы скважиналардан нефть чыгаруны тәэмин итүче төп фондларны мөлкәткә салымның Татарстан Республикасы республика бюджетына күчерелә торган өлешеннән азат итәргә.

2. Нефть чыгаруның яңа алымнарын (гидродинамик, физик-химик, җылылык, газ, геологик-физик һәм микробиологик) куллану хисабына тугыз йөз дә алты мең тонна нефть чыгарырга - һәр тоннасына акциз җыемнарын 15 мең сумга кадәр билгеләргә, минераль ресурс запасларын торгызу өчен түләүдән тулысынча азат итәргә һәм файдалы казылмаларны чыгаруның нәтиҗәлелеген арттырырга.

3. Минераль ресурс запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген күтәрү өчен түләү ставкасын чыгарылган табигый байлыкны сатудан килгән бәяләргә карата 10 проценттан алып 8 процентка кадәр киметергә (моңа өстәлгән бәяләргә салым һәм акцизлар керми).

<u>10 статья.</u> "Алабуга җиңел автомобильләр заводы" җитештерү берләшмәсенең җиңел автомобильләр җитештерү куәтләре булдыруын 1997 елда дәүләт тарафыннан яклау максатында:

1."АлАЗ-ДМ корпорациясе" уртак предприятиесен, "Алабуга җиңел автомобильләр заводы" җитештерү берләшмәсен һәм аның структур бүлекчәләрен юридик зат хокуклары белән табышка са

лымның Татарстан Республикасы бюджетына түләнә торган өлешеннән азат итәргә.

"Алабуга җиңел автомобильләр заводы" җитештерү берләшмәсе һәм юридик зат хокукы булган структур бүлекчәләре җитештерүче товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) өстәлгән бәяләргә салымның Татарстан Республикасы бюджетына кертелүче өлешен түләүдән азат итәргә, шушы акчаларны җиңел автомобильләр җитештерүне финанслауга тотарга.

3. "АлАЗ-ДМ корпорациясе" уртак предприятиесе һәм "Алабуга җиңел автомобильләр заводы" җитештерү берләшмәсе җитештергән җиңел автомобильләргә акциз ставкасын җибәрү бәясенең 0,1 проценты күләмендә билгеләргә.

4. "Алабуга җиңел автомобильләр заводы" җитештерү берләшмәсе милкәтенә салым ставкасын салым салу базасыннан 0,1 процент, дип билгеләргә.

11 статья. 1997 елда Татарстан Республикасының бюджетына түбәндәге бюджеттан тыш фондларның акчаларын тупларга (кертергә):

Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү фонды;

Татарстан Республикасының Янгын куркынычсызлыгы фонды;

Татарстан Республикасының ЭЭМ ДАИ идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фонды;

Татарстан Республикасы Юллар фонды;

Татарстан Республикасы Экология фонды;

Татарстан Республикасы Хосусыйлаштыру фонды;

Гомум тармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә конструкторлык эшләренең (НИОКР) республика фонды;

Татарстан Республикасының Минераль ресурслар запасларын яңадан торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды;

Республика сырхаухана кассасы;

Районнарны, шәһәрләрне һәм авылларны газлаштыру буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы бюджеттан тыш дәүләт фонды.

12 статья. 1997 елга Татарстан Республикасының республика бюджетына төп чыганаклар буенча керемнәрнең килерен түбәндәге суммаларда дип исәпләргә:

(млн.сумнарда)

| | |
|---|---|
| - Салым керемнәре - барлыгы | 5307294 |
| шул исәптән: | |
| - предприятиеләр һәм оешмалар табышына керемнәргә салым | 777172 |
| - физик затлардан керем салымы | 255362 |
| - өстәлгән бәяләргә салым | 1759000 |
| - акцизлар, | 1098000 |
| шул исәптән азык чималыннан алынучы этил спиртына акцизлар | 570800 |
| - лицензия җыемнары | 300000 |
| - предприятиеләр мөлкәтенә салым | 382331 |
| - кыйммәтле кәгазьләр белән эш иткән өчен салым | 5500 |
| - табигый байлыклардан файдаланган өчен түләүләр | 304960 |
| - җир салымы һәм җир өчен аренда түләве | 151709 |
| башка төрле салымнар, җыемнар һәм керемнәр | 273260 |
| | |
| Салымга карамаган керемнәр - барлыгы | 1642311 |
| шул исәптән: | |
| - дәүләт мөлкәтен сатудан килгән керемнәр | 572000 |
| - тышкы икътисадый эшчәнлектән килгән керемнәр | 250000 |
| - 1996 елда кире кайтару шарты белән бирелгән акчаларның килере | 703200 |
| - салым булмаган башка керемнәр | 117111 |

| | |
|---|---|
| Түбәнгерәк бюджетлардан алынырга тиешле акчалар | 89453 |
| Бюджеттан тыш фонд керемнәре - барлыгы | 4450100 |
| шул исәптән: | |
| Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү фонды | 363000 |
| Татарстан Республикасының Янгын куркынычсызлыгы фонды | 5000 |
| Татарстан Республикасының ЭЭМ ДАИ идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фонды | 13000 |
| Татарстан Республикасы Юллар фонды | 1823000 |
| Татарстан Республикасы Экология фонды | 125000 |
| Татарстан Республикасы Хосусыйлаштыру фонды | 97000 |
| Гомум тармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләренең (НИОКР) фонды | 480000 |
| Татарстан Республикасының Минераль ресурслар запасларын яңадан торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды | 931000 |
| Республика сырхауханә кассасы | 190100 |
| Районнарны, шәһәрләрне һәм авылларны газлаштыру буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы бюджеттан тыш дәүләт фонды | 423000 |

13 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты республиканың кыска вакытлы облигацияләре эмиссиясенең иң чик күләмен 1997 елда 1500 млрд.сум дип билгеләргә тиеш.

14 статья. 1997 елда Татарстан Республикасының республика бюджетына керә торган салым һәм башка мәҗбүри түләүләрнең бер өлеше буенча бирелгән кичектерүләр (кетәчәкләр) өчен Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанс ставкаларының өчтән икесе күләмендә бюджет акчаларыннан файдаланган өчен процентлар рәвешендә түләү алына.

15 статья. 1997 елда район һәм шәһәр бюджетларына түбәндәге салымнарны тапшырырга:

- предприятиеләрнең һәм оешмаларның табышына (керемена) салым - салым салынучы табышның 22%ы күләмендә, ә кайбер районнарга һәм шәһәрләргә түбәндәгечә бирелә:

Азнакай районына һәм шәһәренә - 11%, Әлмәт районына һәм шәһәренә - 5%, Баулы районына - 20%, Бөгелмә районына һәм шәһәренә - 12%, Зәй районына һәм шәһәренә - 20%, Лениногорск районына һәм шәһәренә - 7 %, Октябрь районына - 15%, Сарман районына - 3%, Тукай районына - 11%, Чаллы шәһәренә - 19%, Түбән Кама шәһәренә - 7%;

- предприятиеләрдә, учреждениеләрдә һәм оешмаларда тотылып калучы физик затлардан керем салымы, түбәндәгеләрдән тыш, 11% лы ставка буенча:

Азнакай районына һәм шәһәренә - 63%, Әлмәт районына һәм шәһәренә - 20%, Баулы районына - 50%, Бөгелмә районына һәм шәһәренә- 54 %, Зәй районына һәм шәһәренә - 59%, Лениногорск районына һәм шәһәренә - 89% һәм Түбән Кама шәһәренә - 45%;

- предприятиеләрнең һәм оешмаларның милкәтенә салым, түбәндәгеләрдән тыш, 100% күләмендә:

Азнакай районына һәм шәһәренә - 53%, Әлмәт районына һәм шәһәренә - 91%, Баулы районына - 50%, Бөгелмә районына һәм шәһәренә - 53%, Зәй районына һәм шәһәренә - 50%, Лениногорск районына һәм шәһәренә - 50%, Сарман районына - 20%, Тукай районына - 96%, Түбән Кама шәһәренә - 51%.

16 статья. 1997 елгы республика бюджетында агымдагы чыгымнарны финанслау өчен ассигнованиеләрнең гомуми күләмен - 7403159 млн. сум итеп, үсеш бюджетын финанслау өчен, капитал салуларны да кертеп, 5561743 млн.сум итеп билгеләргә.

17 статья. 1997 елда республика бюджетыннан 12964902 млн.сум күләмендә ассигнованиеләрне түбәндәге максатларга юнәлтергә:

(млн.сумнарда)

| | Барысы | шул исәптән | |
|---|---|---|---|
| | | агымдагы чыгымнар бюджеты | үсеш бюджеты |
| 1. Дәүләт идарәсенә | 152021 | 152021 | |
| 2. Тышкы икътисадый эшчәнлек чыгымнарына | 250000 | 250000 | |
| 3. Хокук саклау эшчәнлеге һәм куркынычсызлык тәэмин итүгә | 629322 | 561364 | 67958 |
| 4. Фәнгә | 23000 | 23000 | |
| 5. Промышленностька, энергетикага һәм төзелешкә | | | |
| - халыкка ягулык өчен дотациягә (каты ягулыкка һәм газга) | 52134 | 52134 | |
| - 1992 елның 1 гыйнварена кадәр төзи башланган торак-кооператив төзелешенең кыйммәтләнүен компенсацияләүгә | 6050 | | 6050 |
| Проект эшләренә | 350 | | 350 |
| - вак эшкуарлыкны яклауга (кире кайтару шарты белән) | 50000 | | 50000 |
| - республика инвестиция программасына, | 1327000 | | 1327000 |
| шул исәптән "АлАЗга" | 120000 | | 120000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. Авыл хуҗалыгына | | | |
| - авыл хуҗалыгына | 1390746 | 1180936 | 209810 |
| -терлекчелек продукциясен дотацияләүгә | 320000 | 320000 | |
| - Ветеринариянең баш идарәсенә | 19100 | 19100 | |
| - җир өчен түләү исәбеннән чыгымнарга, | 151709 | 151709 | |
| шул исәптән җирләрне тамырдан яхшыртуга | 100000 | 100000 | |
| - икмәккә һәм азык-төлек товарларына бәяләр аермасын каплауга | 20000 | 20000 | |
| - азык-төлек товарлары буенча дәүләт заказын барлыкка китерүгә (кире кайтару шарты белән) | 650000 | 650000 | |
| 7. Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклауга: | | | |
| - урман хуҗалыгына | 82000 | 70000 | 12000 |
| - әйләнә-тирә табигать мохитен саклауга | 38000 | 14000 | 24000 |
| 8. Транспортка: | | | |
| - автомобиль транспортына | 77930 | 47930 | 30000 |
| - су юлы транспортына | 13930 | 13930 | |
| - һава юлы транспортына | 6610 | 6610 | |
| - тимер юл транспортына | 29230 | 29230 | |
| 9. Торак-коммуналь хуҗалыгына | 56070 | 36070 | 20000 |
| 10. Яңадан тапшырылучы ведомство торак фондын һәм социаль-мәдәни өлкә объектларын тотуга | 166000 | 166000 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 11. | Гадәттән тыш хәлләрне һәм табигый бәла-казаларны кисәтү һәм бетерү өчен | 4000 | 4000 | |
| 12. | Мәгарифкә, | 317962 | 223962 | 94000 |
| | шул исәптән Татар гуманитар институтына | 6000 | 6000 | |
| 13. | Мәдәнияткә һәм сәнгатькә | | | |
| | - мәдәнияткә һәм сәнгатькә | 142000 | 95745 | 46255 |
| | - кинематографиягә | 14254 | 6254 | 8000 |
| | - Милли-мәдәни җәмгыятьләр ассоциациясенә | 150 | 150 | |
| 14. | "Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында" Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру буенча гамәлләргә | 5808 | 5808 | |
| 15. | Массакүләм мәгълүмат чараларына: | | | |
| | - телевидение һәм радиога | 27573 | 24573 | 3000 |
| | - көндәлек матбугатка һәм нәшриятларга | 41178 | 35178 | 6000 |
| 16. | Сәламәтлек саклауга һәм физик тәрбиягә: | | | |
| | - сәламәтлек саклауга | 525647 | 416247 | 109400 |
| | - Санэпидкүзәтү буенча дәүләт комитетына | 70430 | 64980 | 5450 |
| | - физик тәрбиягә | 22040 | 22040 | |
| 17. | Социаль сәясәткә: | | | |
| | - социаль тәэминат учреждениеләренә | 80000 | 76730 | 3270 |
| | - яшьләр сәясәтенә | 7425 | 6225 | 1200 |
| | - социаль яклау гамәлләренә | 190878 | 190878 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 18. Башка чыгымнарга: | | | |
| - Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең резерв фондына | 80000 | 80000 | |
| - районнарга һәм шәһәрләргә финанс ярдәменә (дотация) | 1158255 | 1158255 | |
| - былтырдан калган бурычны түләү өчен резервка | 110000 | 110000 | |
| 19. Озак срoклы һәм уртача срoклы кредитларны тәэмин итүгә | 200000 | 200000 | |
| 20. Бюджеттан тыш дәүләт фондлары чыгымнары | 4550100 | 1162100 | 3288000 |
| Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фонды | 36300 | 255200 | 107800 |
| Татарстан Республикасының Янгын куркынычсызлыгы фонды | 5000 | 5000 | |
| Татарстан ЭЭМ ДАИ идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фонды | 13000 | 8500 | 4500 |
| Татарстан Республикасы Юллар фонды | 1823000 | 13000 | 1810000 |
| Татарстан Республикасы Экология фонды | 125000 | 125000 | |
| Татарстан Республикасы Хосусыйлаштыру фонды | 97000 | 97000 | |
| Гомум тармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләренең (НИОКР) республика фонды | 480000 | 151200 | 328800 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасының Минераль ресурслар запасларын яңадан торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды | 931000 | 119800 | 811200 |
| Республика сырхауханә кассасы | 190100 | 190100 | - |
| Районнарны, шәһәрләрне һәм авылларны газлаштыру буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы бюджеттан тыш дәүләт фонды | 423000 | 197300 | 225700 |

<u>18 статья.</u> Авыл хуҗалыгы өчен бюджет акчаларын бүлүне әлеге Законның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

<u>19 статья.</u> 1997 елда дәүләт хакимиятен гамәлгә ашыру өчен чыгымнарны 152021 млн.сум күләмендә расларга, шул исәптән:

түбәндәгеләрнең эшчәнлеген финанслау өчен чыгымнар:

(млн.сумнарда)

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Президентының, Президент Аппаратының | 8601 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының, даими эшләүче халык депутатларының | 17111 |
| Татарстан Республикасы халык депутатларына депутат вәкаләтләрен башкару белән бәйле чыгымнарны түләүгә | 312 |
| Закон проектларын эшләү һәм аларга экспертиза ясауга бәйле чыгымнарга | 1000 |

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләрен үткәрүгә бәйле чыгымнарга | 2000 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Парламент контроле комитетына | 1100 |
| Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына | 10581 |
| Татарстан Республикасы министрлыкларына, дәүләт комитетларына, ведомстволарына һәм аларның органнарына | 79527 |
| Татарстан Республикасы Югары арбитраж судына | 3400 |
| Татарстан Республикасының Конституция күзәтчелеге комитетына | 500 |
| Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенә, | 1655 |
| шул исәптән: Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлауларны уздыруга | 1051 |
| Татарстан Республикасы вәкилләкләренә | 7502 |
| Архив учреждениеләрен финанслау чыгымнары | 6732 |
| "Дәүләт хезмәте турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чыгымнары | 12000 |

20 статья. Бюджетта каралган гамәлләрнең эзлекле финанслануын тәэмин итү йөзеннән, 1997 елда Татарстан Республикасының республика бюджетыннан районнар һәм шәһәрләр бюджетларына 1158255 млн.сум күләмендә дотация бүлеп бирергә, шул исәптән:

(млн.сумнарда)

| | |
|---|---|
| Аксубай районы | 34880 |
| Актаныш | 34904 |
| Алексеевск | 34500 |
| Апас | 24818 |
| Алабуга | 35083 |
| Арча | 41249 |
| Балтач | 38067 |
| Балык Бистәсе | 32781 |
| Биектау | 17198 |
| Буа | 37435 |
| Зеленодол | 29258 |
| Кайбыч | 16928 |
| Кама Тамагы | 18762 |
| Кукмара | 46695 |
| Лаеш | 28652 |
| Мамадыш | 43025 |
| Менделеевск | 7846 |
| Минзәлә | 22016 |
| Мөслим | 26335 |
| Питрәч | 30166 |
| Саба | 33436 |
| Спас | 32423 |
| Теләче | 16284 |
| Тәтеш | 33281 |
| Түбән Кама | 52786 |
| Чирмешән | 22708 |
| Чистай | 23646 |
| Чүпрәле | 30809 |
| Югары Ослан | 20678 |
| Ютазы | 11327 |
| Яңа Чишмә | 19808 |

| | |
|---|---|
| Әгерҗе | 25963 |
| Әлки | 31684 |
| Әтнә | 16926 |
| | |
| Зеленодол шәһәре | 76662 |
| Чистай шәһәре | 22980 |
| Казан шәһәре | 86256 |

21 статья. 1998 елның 1 гыйнварена Татарстан Республикасы республика бюджетының касса әйләнешендәге акчаларын 350 млрд.сум күләмендә расларга.

22 статья. 1997 елда Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына бюджет өлкәсендәге, шул исәптән идарә аппаратының да, хезмәткәрләр санын арттыруга китерә торган карарларны кабул итмәскә.

23 статья. 1997 елга Татарстан Республикасы республика бюджетының тулы күләмдә финанслана торган якланучан агымдагы чыгымнарының түбәндәге исемлеген расларга: Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фондының һәм Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча Пенсия фондының, мәҗбүри медицина һәм социаль иминлек кертемнәрен һәм түләүләрен дә исәпкә алып, хезмәт хакы; стипендияләр; дәүләт пособиеләре, балаларга пособиеләр түләү һәм мәктәп балаларын тукландыруга дотацияләр, халыкка башка социаль һәм компенсация түләүләре; тукландыру; медикаментлар һәм яраларны бәйләү чаралары сатып алу; хезмәт хакы түләү өчен җирле бюджетка күчерелүче дотацияләр, хезмәт хакы өлешендә.

24 статья. 1997 елга республика бюджеты акчалары хисабыннан өстәмә чыгымнар таләп итүче, шулай ук аның керем базасын киметүче законнар һәм норматив-хокукый актлар Татарстан Республикасының республика бюджетында өстәмә керемнәр булганда һәм (яисә) конкрет бюджет статьялары буенча чыгымнар кыскарганда гына гамәлгә ашырыла,дип билгеләргә.

25 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты һәм Татарстан Республикасы Милли банкы 1996 елда Татарстан Республикасының республика һәм җирле бюджетлары чыгымнарының һәм керемнәренең исәп-хисабы, үтәлеше системасын оештыруны һәм аның нәтиҗәле эшен тәэмин итәргә тиеш.

Бюджетларның касса үтәлеше буенча гамәлләре, комиссион түләүләр алынмаган килеш, Татарстан Республикасы Милли банкы яки Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкаләт биргән банклар тарафыннан башкарыла, дип билгеләргә.

26 статья. Татарстан Республикасы республика бюджетының кайбер бүлекләре буенча 1996 елда җитәрлек дәрәҗәдә финансланмау бары тик әлеге Законның 16 статьясында билгеләнгән 1997 елгы республика бюджеты ассигнованиеләре хисабына һәм шул чикләрдә генә компенсацияләнә дип билгеләргә.

27 статья. Тиешле норматив актлар кабул ителгәнче, "Дәүләт хезмәте турында"гы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 3,4,8,11 пунктларына, 15 статьяга бәйле чыгымнарны түләмәскә, моңа әлек кабул ителгән законнар нигезендә дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү, матди һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү шартлары керми.

28 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты 17 статьяның 5 пунктында каралган Республика инвестицияләү программасын Татарстан Республикасының шәһәрләренә һәм районнарына бүлеп бирергә һәм "1997 елга Татарстан Республикасы бюджет системасы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чираттагы сессиясенә кертергә тиеш.

29 статья. Әлеге Законны кабул ителгән көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 28 декабре
N 951